ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ АКХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2018 ел, 1 октябрь №74/2

**Җирлек җирле үзидарә органнрына муниципаль район җирле үзидарә органнарының аерым җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә:

- җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән документларны раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларны раслау.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советына

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне билгеләнгән форма нигезендә тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турында Карары проектын бюджет законнары нигезендә карап тикшерүгә әзерләргә һәм тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны җирлек уставы нигезендә бастырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Акхуҗа авыл
җирлеге башлыгы З.Я.Юзеев